**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 8 апрелендәге 1054 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2013 елның 5 июнендәге 5339 номерлы**
**«Казан шәһәре территориясендә җәяүле туристлык маршрутлары буенча төзекләндерү элементларын урнаштыру схемасын, төзекләндерү элементлары типологиясен, каты көнкүреш калдыкларын саклау мәйданчыклары типологиясен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Шәһәр мохите эстетикасын яхшырту максатыннан, Казан шәһәр Думасының 2012 елның 7 июнендәге 4-14 номерлы «Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 5 июнендәге 5339 номерлы «Казан шәһәре территориясендә җәяүле туристлык маршрутлары буенча төзекләндерү элементларын урнаштыру схемасын, төзекләндерү элементлары типологиясен, каты көнкүреш калдыкларын саклау мәйданчыклары типологиясен раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 15 маендагы 2046 номерлы, 2016 елның 20 июнендәге 2495 номерлы, 2019 елның 30 маендагы 2004 номерлы, 2020 елның 26 мартындагы 923 номерлы, 2021 елның 16 июнендәге 1484 номерлы, 2022 елның 31 гыйнварындагы 925 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар атамасында, 2(1), 7 пунктларда «көнкүреш» сүзен «коммуналь» сүзенә алмаштырырга;

1.2. 13 номерлы кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә редакцияләргә;


2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 8 апрелендәге
1054 номерлы карарына
кушымта

**Урам җиһазлары типологиясе**

<table>
<tr><td>2 нче тип</td><td colspan="4">КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ ЗАМАНЧА ӨЛЕШЕНДӘ УРНАШТЫРУ ӨЧЕН</td></tr>
<tr><td rowspan="3">КАТЫ КӨНКҮРЕШ КАЛДЫКЛАРЫН САКЛАУ МӘЙДАНЧЫКЛАРЫ ТИПОЛОГИЯСЕ</td><td colspan="4"><br><br></td></tr>
<tr><td colspan="4">*МОДУЛЬНЕҢ ПЛАНЛАШТЫРУ ГАБАРИТЛАРЫН ҖИР КИШӘРЛЕКЛӘРЕ ХАРАКТЕРИСТИКАЛАРЫН ИСӘПКӘ АЛЫП ҮЗГӘРТҮ РӨХСӘТ ИТЕЛӘ</td></tr>
<tr><td>КАРКАС</td><td>RAL 7037, 7012</td><td>ТЫШЛЫК</td><td>RAL 7038, 7045</td></tr>
</table>